ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

26.12.2020 г.Казань № 418-од

Буфер зоналары турында

Татарстан Республикасы территориясендә африка дуңгызлар чумасы вирусы ачыклануга бәйле рәвештә һәм аның таралуын булдырмау максаты белән, Татарстан Республикасы территориясенә африка чумасы үтеп керүне һәм аның таралуын булдырмау буенча республика штабының 25.12.2020 ел, 54нче номерлы карары нигезендә, **боерам:**

1. Россия Федерациясенең башка субъектлары белән уртак чикләре булган Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында, әлеге чикләрдән 20 километр арада;

1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасының дуңгызчылык хуҗалыклары тирәсендә 10 километр радиуста;

«Камский бекон» ҖЧҖ, «ТатМитАгро» ҖЧҖ, «Авангард»ҖЧҖ дуңгызчылык предприятиеләре тирәсендә 20 километр радиуста буфер зоналарын оештырырга.

2. 2 нче кушымта нигезендә буфер зоналары режимын билгеләргә.

3. Барлык аучылык өлкәсендә эшләүчеләргә, хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аеруча саклаулы табигать территорияләре өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлек башлыкларына һәм җитәкчеләренә, региональ әһәмияттәге дәүләт табигый тыюлыкларының администрация башлыкларына буфер зоналары режимын үтәү буенча чаралар күрергә.

4. Хайваннар дөньясын күзәтү бүлеге башлыгына буфер зоналарын оештыру һәм аның режимы турындагы мәгълүматны барлык аучылык өлкәсендә эшләүчеләргә, хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аеруча саклаулы табигать территорияләре өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлек

башлыкларына һәм җитәкчеләренә, региональ әһәмияттәге дәүләт табигый тыюлыкларының администрация башлыкларына җиткерергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне комитет рәисе урынбасары Р. Г. Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Рәис урынбасары Ю.Б. Матвеев

Татарстан Республикасы Биологик
ресурслар буенча дәүләт комитетының
2020 елның 26 нчы декабреннән 418-
од номерлы боерыгына 1 нче кушымта

Янында 10 километрлы буфер зонасы оештырылган дуңгызчылык предприятиеләренең исемлеге

| № п/п | Район | Хуҗалык исемлеге |
|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | «Нәүрүз» ҖЧҖ |
| 2 | Әлки | «Салман» ҖЧҖ СФ |
| 3 | Баулы | «Минуллин Г.С.» КФХ |
| 4 | Балтач | «Яңа Тормыш» ҖЧҖ |
| 5 | Балтач | «Труд» ҖЧҖ |
| 6 | Бөгелмә | «М.Джалиль ис.» ҖЧҖ |
| 7 | Югары Ослан | «Пашков С.И.» КФХ |
| 8 | Лениногорск | Агрофирма «Ялтау» ҖЧҖ |
| 9 | Менделеевск | Шәхси эшмәкәр Габдрахманов Р.Г. |
| 10 | Сарман | «Сафина» КФХ |
| 11 | Тукай | «Феникс» ҖЧҖ |

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 26 нчы декабреннән 418-од номерлы боерыгына 2 нче кушымта

## Буфер зоналарының режимы

1. Буфер зонасы территориясенә кыргый кабаннарны кертмәү.
2. Буфер зоналарыннан кабаннарны максималь рәвештә чыгаруны тәэмин итү.
3. Буфер зонасында кабаннарны аулаганда куркытуны күздә тоткан ау методларын куллануны тыю.
4. Кыргый кабаннарны өлешләргә бүлүне тыю.
5. Буфер зонасында җимлекләр урнаштыруга һәм кабаннарны тукландыруга тыю.
6. Кыргый кабаннарны тоту өчен вольерлар урнаштыруны тыю
7. Буфер зонасы янында мониторинг үткәрү.
8. Буфер зонасы территориясендә билгесез сәбәпләр аркасында һәлак булган кабаннарны табу очрагында, үлү урынында түшкә башка хайваннар белән контактка кермәслек чаралар күреп, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты һәм районның дәүләт ветеринария хезмәте учреждениеләренә кичекмәстән хәбәр итү.